Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең
Иске Суркино торакпунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

26 ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021елның 26 ноябрендәге 15 сәгать 00 минутта, 2021 елның 26 ноябрендәге 16 сәгать 00 минутта, 2021 елның 26 ноябрендәге 17 сәгать 00 минутта, 2021 елның 26 ноябрендәге 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлеге Иске Суркино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 566 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 295 кеше, бу 52,1% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 295 «РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде, җыенда катнашучы 0 кеше "ТЫЕЛЫП” торды

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыИске Суркино авыл җирлегенең Иске Суркиноавылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салымсредстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү һәм авыл җирлеге милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетысында бастырырга,Иске Суркино авылы, Үзәк урам, 77 нче йорттерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.В. Леонтьев